**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасын раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасын раслау турында» 2011 елның 24 сентябрендәге ПУ-585 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 20 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2013 елның 11 сентябрендәге ПУ-892 номерлы, 2014 елның 6 мартындагы ПУ-258 номерлы, 2014 елның 19 апрелендәге ПУ-405 номерлы, 2015 елның 8 июнендәге ПУ-543 номерлы, 2016 елның 12 августындагы ПУ-683 номерлы, 2016 елның 6 декабрендәге ПУ-1075 номерлы һәм 2019 елның 23 декабрендәге ПУ-788 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктның икенче абзацында «, тапшырылган вәкаләтләр мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары кабул итүче норматив хокукый актларның нөсхәләрен» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасын кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 25 ноябрь
№ ПУ-777

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «25» ноябрендәге
ПУ-777 номерлы Указына
кушымта

## Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасы

